Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы
башкарма комитетының "Мәктәпкәчә мәгариф идарәсе"
муниципаль учреждениесе

«25 нче гомуми үстерешле балалар бакчасы»

| | |
|---|---|
| Расланды: | Килешенде: |
| 25 нче балалар бакчасы | 39 нчы балалар бакчасы |
| мөдире | өлкән тәрбиячесе |
| ________________ | ________________ |
| Хузягалиева Г. М. | Мирхазова Н.Р. |
| 07.04.2011 | 12.04.2011 |



# Еллар түгел, гасырлар да үтәр,
# Онытa алмас сине, Тукай, сөйгән халкың.

Шәһәр күләмендә уздырылган Габдулла Тукайның 125 еллык
юбилеена багышланган кичәдә чыгыш


Төзеде:
25 нче балалар бакчасы
тәрбиячесе Гильмутдинова
Лилия Разиф кызы.



Татарстан.
Түбән Кама.
2011

Дөньяда бик аз буладыр чын шагыйрь Габдулладай;
Ул караңгы төндә яктыртылган матур тулган ай...
Алса, укыса халык шигырен аның – истә кала,
Һәм аның шигыре халыкның күңеленә зур хис сала.

| | |
|---|---|
| 1<br><br> | 2. 1925 елда Казанда Г.Тукай исемендәге мәйдан ачыла.<br><br> |
| 1958 ел- Казан күле буендагы бакчада Г. Тукай истәлегенә икенче һәйкәл куела.<br>Авторлар: Л. Павлов, Л. Кербер, Л. Писаревсий , С. Ахун. | |
| 3.1955 ел – Кушлавыч авылында Г.Тукайга һәйкәл куела. Автор: скульптор И.А.Новоселов. | <br> |
| 4. 1956 ел – Казанда Г.Тукайга | |

| | |
|---|---|
| беренче һәйкәл куела. Ул Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры янында урнашкан. Авторы Е.Шулик.<br>26нчы апрельдә Казанда элек бер Шигырь бәйрәме генә булса, хәзер ике бәйрәм үтә. Габдулла Тукай һәйкәле янындагы Шигырь бәйрәменнән тыш, Бауман һәм Университет урамнары кисешкән урында “Мин татарча сөйләшәм” акциясе **дә уза.** |  |
| 1958 ел- Казан күле буендагы бакчада Г. Тукай истәлегенә икенче һәйкәл куела.<br>Авторлар: Л. Павлов, Л. Кербер, Л. Писаревсий , С. Ахун. |  |
| 5. 1971 ел – Казан артының Арча районы Яңа Кырлай авылында Г.Тукай әдәби мемориаль музее, беренче тапкыр авыл китапханәсе бинасында ачыла. |   |

| | |
|---|---|
| 1979 елның 25 апрелендә Яңа Кырлайда Б.Урманче проекты белән Г. Тукайга багышланган яңа музей бинасы төзелә.. Музей комплексы үз эченә ике экспозицияне ала: мемориаль көнкүреш (Сәгъди абзый йорты) һәм әдәби-нәфис (махсус төзелгән бина). "Г. Тукайның тормышы һәм иҗаты" дигән экспозия Б. Урманче проекты белән төзелгән ике катлы бинада урын алган. |  |
| **Габдулла Тукайны бәләкәй вакытында үзенә сыендырган Яңа Кырлай авылы (Татарстанның Арча муниципаль районында) үзе үк мемориаль һәйкәл булып тора. Кырлай авылында Сәгъди абзыйлар гаиләсендә Тукай 5 елга якын яши. Тукайның гади крестьян тормышының көндәлеге, ихтыяҗын сиземләве шушы Кырлайдан башлана. Монда ул мәдрәсәгә йөреп белем ала, халык иҗаты гәүһәрләре белән таныша. "Бу Кырлай авылы минем дөньяга иң элек күзем ачылган урыным", - дип язды соңыннан шагыйрь.** |  |
| 1972 ел, декабрь – Түбән Камада Г.Тукай исемендәге милли китапханә ачыла. |  |

| | |
|---|---|
| | |
| |  |
| | |
| • 1976 ел - Яңа Кырлай авылындагы Г.Тукай әдәби мемориаль музее территориясендә һәйкәл ачыла. Автор: скульптор Б.Урманче. |  |
| • 1986 ел, февраль - Түбән Камада Тукай бюсты куела. Авторлар: П.Д.Бегенев, Р.С.Шигабутдинов, М.С.Юсупов. |  |
| • 1986 ел – Казанда Г.Тукай музее ачыла, Тукай урамындагы 74 нче йортка урнашкан. | |


















- Уфа, Баку, Ташкент, Уральск шәһәрләрендә Г.Тукай исемендәге урамнар бар. Петербург шәһәрендә, элекке татар бистәсеннән ерак түгел урында Г.Тукайга һәйкәл куелган.




| | |
|---|---|
| |  |
| 1991 ел. Түбән Кама каласы үзенең 25 еллыгын билгеләп үтте. Шул көннәрне яшьлек шәһәрендә халкыбызның сөекле шагыйре Г.Тукайга һәйкәл ачылды. Автор: скульптор Б.Урманче. |  |
| Шушы ук елны "Кояшлы" урамын Г.Тукай исеменә үзгәртәләр. | |
| • 1996 ел – Кушлавыч авылында музей-йорт ачылды. |  |
|  |  |










Милли мультфильмнар төшерү – республикабызның гаять бай мәдәни байлыгы – Габдулла Тукайның иҗади мирасын саклау һәм үстерүнең ышанычлы юлы. Шагыйрьнең 125 еллык юбилеен бәйрәм итү уңаеннан бу мәсьәлә бигрәк тә актуальләшә.

Әлеге мультфильмнар балалар аңында югары кешелеклелек принциплары тәрбияләргә һәм үсеп килүче буында милли мәдәни мирас кызыксыну уятырга, туган тел һәм тарих байлыкларын өйрәнергә хезмәт итәчәк.



Мәскәүдә гыйнвар аеннан башлап Тукайга багышланган чаралар үтә. Шушы көннәрдә Пушкин музеенда Габдулла Тукайның туына 125 ел тулуга багышланган күргәзмә ачылды.

| | |
|---|---|
| Чиратта – “Энҗе бөртекләре” балалар фестивале. 26 апрель көнне Мәдәни үзәк каршында Габдулла Тукайга һәйкәл ачылу көтелә. |   |
| | |